**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 02 » 11 2021 № 342

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Суд тарафыннан эшкә
сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән дип танылган
балигъ булган гражданнарга һәм балигъ булмаган гражданнарга
карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре
күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»
2018 ел, 25 декабрь, 732 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 17.09.2021 ел, № 7912 боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 26.08.2021 ел, № под-1117/21; 26.08.2021 ел, № под-1112/21 боерыклары, «Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 17.09.2021 ел, № 04/13-06/4643 хаты, "Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында» 20.09.2021 ел, № 04/13-06/4672 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының хаты нигезендә, Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган гражданнарга һәм балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 ел, 25 декабрь, 732 нче карарына (26.02.2021 ел, № 67; 29.03.2021 ел, № 93; 12.04.2021 ел, № 113 карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Опекунга яки попечительгә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга баланы (балаларны) тоту өчен акча билгеләү һәм түләү буенча, шулай ук үз вазыйфаларын түләүле үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүне түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты» 1.11. пунктчасын төшереп калдырырга (11 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыкларын:
- «Опекун (попечитель) һәм тәрбиягә бала алган гаиләдә баланы карап тоту өчен айлык түләүне билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 26.08.2021 ел, № под-1117/21;
- «Опека, попечительлек (шул исәптән алдан опека, попечительлек) билгеләү, опекунны (попечительне) үз бурычларын үтәүдән азат итү (балигъ булмаганнарга карата) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 26.08.2021 ел, № под-1112/21- Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев